| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль, 2020 ел Олы Кайбыч авылы № 1

«Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Наратлы, Юл, Чыршылы, Миләшле һәм Урман урамнары буенча күп балалы гаиләләр өчен төзелә торган 80 торак йортны газ бүлү челтәрләренә тоташтыру» линия объектын ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү хакында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Уставына таянып, халык алдында тыңлауларда катнашу хокукларын үтәү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. «Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Наратлы, Юл, Чыршылы, Миләшле һәм Урман урамнары буенча күп балалы гаиләләр өчен төзелә торган 80 торак йортны газ бүлү челтәрләренә тоташтыру» линия объектын ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. - ачык тыңлауларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә;

- ачык тыңлауларны үткәрү вакыты – 10.03.2020 ел, 10.00 сәг.;

- үткәрү урыны - «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге администрациясенең утырышлар залы (адресы: Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар ур., 7);

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр).

3. Түбәндәге составта «Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Наратлы, Юл, Чыршылы, Миләшле һәм Урман урамнары буенча күп балалы гаиләләр өчен төзелә торган 80 торак йортны газ бүлү челтәрләренә тоташтыру» линия объектын ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем төзергә:

**Эшче төркем рәисе:**

Макаров Алексей Николаевич – Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);

**Эшче төркем рәисе урынбасары:**

Әхмәтов Фирдүс Шәрифович –Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);

**Эшче төркем әгъзалары:**

Сәлахов Булат Ринатович –Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Хәмидуллин Ильяс Илдарович – «Буа газы» ЭПУ Кайбыч РЭГС начальнигы (килешү буенча);

Сафин Рәмис Багдетдинович –Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);

Зиннуров Фәннур Рәшитович - «Кайбыч ТКХ» МУП директоры (килешү буенча).

4. Әлеге карарны Олы Кайбыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин

Совет Большекайбицкого сельского поселения
Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы
ИНН 1621000502
ОГРН 1021606764497